Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Сәрдекбаш авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

2023 елның «14» ноябре № 10

**Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Бакчасарай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 29 ноябренә 12 сәгать 30 минутка Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Бакчасарай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Бакчасарай поселогы, Яшел урам, 16 адресы буенча урнашкан мәчет бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге Бакчасарай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан; 85 яшькә житкән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бакчасарай бистәсендә юлларга асфальт җәю, ремонтлау, вак таш җәю, юлларны карап тоту; проект смета документлары һәм проектларга экспертиза; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү: янгын гидрантларын урнаштыру, янгын сүндерү инвентаре сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсуслаштырылган машинаны карап тоту, янгын сүндерү техникасын, ДПО тоту чыгымнары, янгын гидрантларын карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Бакчасарай авылы урам юл челтәрен карап тоту;

- зиратны карап тоту буенча эшләрне оештыру, Бакчасарай поселогында зират өчен җиһазлар һәм инвентарьлар сатып алу; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Бакчасарай поселогына видеокүзәтү сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту;
- Бакчасарай поселогында урамнарны яктыртуны карап тору; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Бакчасарай поселогы территориясен төзекләндерүне оештыру; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Бакчасарай поселогына балалар уен мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Байлангар авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сардекбаш авыл
җирлеге башлыгы: И.М. Нәбиев